КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 4 июнь г.Казань № 403

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге концедент булган һәм өченче ягы мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы булган җылылык белән тәэмин итү объектларына, кайнар су белән тәэмин итүнең, салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су чыгаруның үзәкләштерелгән системаларына, мондый системаларның аерым объектларына карата концессия килешүләрен әзерләгәндә, төзегәндә, үзгәрткәндә һәм туктатканда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының ведомствоара хезмәттәшлек тәртибен раслау турында» 2022 ел, 16 февраль, 132 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге концедент булган һәм өченче ягы мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы булган җылылык белән тәэмин итү объектларына, кайнар су белән тәэмин итүнең, салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су чыгаруның үзәкләштерелгән системаларына, мондый системаларның аерым объектларына карата концессия килешүләрен әзерләгәндә, төзегәндә, үзгәрткәндә һәм туктатканда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының ведомствоара хезмәттәшлек тәртибен раслау турында» 2022 ел, 16 февраль, 132 нче

карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының үзара хезмәттәшлеген һәм координациясен тәэмин итү максатларында» сүзләрен «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статья-сындагы 2 өлешен гамәлгә ашыру, шулай ук республика башкарма хакимият органнарының үзара хезмәттәшлеген һәм координациясен тәэмин итү максат-ларында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге концедент булган һәм өченче ягы мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы булган җылылык белән тәэмин итү объектларына, кайнар су белән тәэмин итүнең, салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су чыгаруның үзәкләштерелгән системаларына, мондый системаларның аерым объектларына карата концессия килешүләрен әзерләгәндә, төзегәндә, үзгәрткәндә һәм туктатканда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә:

I бүлектә:

1.3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

1.4 пунктта «әлеге Тәртипнең 1.3 пункты нигезендә» сүзләрен «Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Премьер-министры» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

1.7 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

II бүлектә:

исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«координацияләү органына – җитәкче яисә вәкаләтле зат имзасы белән таныкланган иярчен хат теркәп, тәкъдим һәм аңа теркәлгән концессия килешүе проекты күчермәләре, шулай ук концессия килешүе объекты составына керүче күчемсез мөлкәт объектларына муниципаль берәмлекнең милек (биләү һәм аннан файдалану) хокукын таныклый торган документлар күчермәләре, концессия килешүе проектында каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә хокук билгели торган документлар күчермәләре, муниципаль берәмлектә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дәүләт кадастр исәбенә алынмаган һәм (яисә) хокуклары дәүләт теркәвенә алынмаган, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында белешмә булмаган мөлкәткә милек хокукы

барлыкка килү фактын һәм (яисә) шартларын раслый торган документлар күчермәләре (мондый объектлар концессия килешүе объектлары составында булганда), җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм су чыгару схемаларын раслау турындагы карарлар күчермәләре, җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм су чыгару схемаларыннан концессия килешүләре проектларында каралган, формалаштырылган биремнәрнең расланган җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм су чыгару схемаларын туры килүен раслый торган өземтәләр (pdf форматында, текстлы документлар, электрон таблицалар).»;

2.6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль берәмлекнең милек хокукын раслый торган документлар нигезендә концессия килешүе объекты составына керүче күчемсез мөлкәт объектларына, җир кишәрлекләренә хокук билгели торган документлар нигезендә концессия килешүе проектында каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә милек (биләү һәм аннан файдалану) хокукы булуга; муниципаль берәмлекнең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дәүләт кадастр исәбенә алынмаган һәм (яисә) хокуклары дәүләт теркәвенә алынмаган, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында белешмә булмаган мөлкәткә милек хокукы барлыкка килү факты һәм (яисә) шартлары булуга (мондый вакыйганың барлыкка килү хокукын раслый торган документлар нигезендә);»;

2.7 пунктта «җиде» сүзен «биш» сүзенә алмаштырырга;

2.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Тәкъдим һәм аңа теркәлә торган концессия килешүе проекты әлеге Тәртипнең 2.6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килгән очракта, әлеге Тәртипнең 2.1 пунктындагы өченче абзацы нигезендә тәкъдимнең күчермәсе кергән көннән алып җиде календарь көн эчендә координацияләү органы, әлеге Тәртипнең 1.5 пунктында күрсәтелгән очракта, тәкъдимнең күчермәсен һәм аңа теркәлә торган концессия килешүе проектын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җибәрә.»;

2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы координацияләү органыннан тәкъдимнең һәм аңа кушып бирелгән концессия килешүе проектының күчермәсен алган көннән алып биш эш көне эчендә  үз вәкаләтләре чикләрендә концессия килешүе проектын килештерүне яисә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, аны килештерүдән баш тартуны үз эченә алган җавап әзерли һәм аны координацияләү органына җибәрә.»;

2.10 пунктта «каралган бәяләмәләр» сүзләрен «каралган җавап» сүзләренә алмаштырырга, «җыелма» сүзен «йомгаклау» сүзенә алмаштырырга;

9 пунктта «акча» сүзләрен «субсидия» сүзенә алмаштырырга;

2.12 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

III бүлектә:

исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Концессия килешүе төзүгә әзерләнү максатларында, концессия килешүе

төзү хокукына ия конкурс оештыручы җирле үзидарә органы (алга таба – конкурс оештыручы) концессия килешүе төзү турында карар кабул итү датасына кадәр 40 эш көненнән дә соңга калмыйча түбәндәгеләрне җибәрә:

406 номерлы Тарифларны җайга салу кагыйдәләре, 1075 номерлы Тарифларны җайга салу кагыйдәләре нигезендә Дәүләт комитетына – конкурс документларын әзерләү турында гариза, анда Тарифларны җайга салу кагыйдәләренең 62 пунктында, 1075 номерлы Тарифларны җайга салу кагыйдәләренең 91 пунктында билгеләнгән, шул исәптән «Су белән тәэмин итү һәм су чыгару турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законның $41^1$ статьясындагы 8 өлешенең 2 – 8 һәм 13 пунктлары, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законның $28^1$ статьясындагы 7 өлешенең 1 – 7 һәм 11 пунктлары, шулай ук Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 1, 4 – 7 һәм 9 – 11 пунктлары нигезендә Дәүләт комитеты тарафыннан конкурс оештыручыга тапшырылырга тиешле бәяләр, күрсәткечләр һәм параметрлар турында белешмә бирү хакында рәсми сорауны үз эченә алган мәгълүмат күрсәтелә;

«координацияләү органына – концессия килешүе төзү турында карар проектын, шулай ук төзелә торган конкурс документациясе составына керүче концессия килешүе проектын теркәп, иярчен хат, шулай ук концессия килешүе объекты составына керә торган күчемсез мөлкәт объектларына муниципаль берәмлекнең милек (биләү һәм аннан файдалану) хокукын раслый торган документлар күчермәләре; концессия килешүе проектында каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә хокук билгели торган документлар күчермәләре; муниципаль берәмлекнең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дәүләт кадастр исәбенә алынмаган һәм (яисә) хокуклары дәүләт теркәвенә алынмаган, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында белешмә булмаган мөлкәткә милек хокукы барлыкка килү фактын һәм (яисә) шартларын раслый торган документлар күчермәләре (мондый объектлар концессия килешүе объектлары составында булганда); җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм су чыгару схемаларын раслау турындагы карарлар күчермәләре, җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм су чыгару схемаларыннан концессия килешүләре проектларында каралган, формалаштырылган биремнәрнең (чараларның) расланган җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм су чыгару схемаларын туры килүен раслый торган өземтәләр (pdf форматында, текстлы документлар, электрон таблицалар).»;

3.8 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9. Координацияләү органы әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы өченче абзацы нигезендә иярчен хат алган көннән алып җиде эш көне эчендә документларны әлеге Тәртипнең 2.6 пункты нигезендә карап тикшерә һәм:

концессия килешүе проекты әлеге таләпләргә туры килмәгәндә, конкурс оештыручыга, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, концессия килешүе проектын килештерүдән баш тарту турында җибәрә;

концессия килешүе проекты әлеге таләпләргә туры килгәндә, әлеге Тәртипнең 1.5 пунктында күрсәтелгән очракта, концессия килешүе проектын Татарстан

Республикасы Финанс министрлыгына җибәрә.»;

3.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы координацияләү органыннан концессия килешүе проектын алган көннән алып җиде эш көне эчендә үз вәкаләтләре чикләрендә концессия килешүе проектын килештерүне яисә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, аны килештерүдән баш тартуны үз эченә алган җавап әзерли һәм аны координацияләү органына җибәрә.»;

3.11 пунктта «каралган бәяләмәләр» сүзләрен «каралган җавап» сүзләренә алмаштырырга, «җыелма» сүзен «йомгаклау» сүзенә алмаштырырга;

3.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.12. Әлеге Тәртипнең 3.5 пунктында күрсәтелгән Дәүләт комитетыннан алынган йомгаклау бәяләмәсен яисә җавабын исәпкә алып, концессия килешүе проектын килештерү мөмкин булмаганда, концессия килешүе проектын килештерүдә катнашкан һәм аны төзү мөмкин булмавы турында нигезле нәтиҗәләр бирелгән концессия килешүе проектын карау йомгаклары буенча җаваплар биргән республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органы инициативасы буенча, концессия килешүе проекты нигезләмәләрен төгәлләштерү буенча аның белән сөйләшүләрдә катнаша.»;

3.13 пунктта «3.8 пунктында» сүзләрен «3.1 пунктындагы өченче абзацында» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3.14 пунктта «3.8 пунктында» сүзләрен «3.1 пунктындагы өченче абзацында» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «дүрт» сүзен «биш» сүзенә алмаштырырга;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Тәкъдим ителгән концессия килешүе элегрәк килештерелгән концессия килешүе проекты нигезләмәләренә үзгәреш кертмәгән очракта, координацияләү органы әлеге Тәртипнең 4.1 пункты нигезендә концессия килешүе кергән көннән алып өч эш көне эчендә аны Татарстан Республикасы Премьер-министрына килештерүгә җибәрә.

Координацияләү орган концессия килешүен Татарстан Республикасы Премьер-министры белән килештергән көннән алып өч эш көне эчендә аны Татарстан Республикасы Рәисенә кул куюга җибәрә.»;

4.3 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.4 пунктта «Татарстан Республикасы Премьер-министры» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга, «концессия килешүе» сүзләреннән соң «бер нөсхәсе Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә саклана,» сүзләрен өстәргә;

4.8 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.10. Әгәр өстәмә килешүдә республика башкарма хакимияте органнары белән килештерелгән өстәмә килешү проектының нигезләмәләренә үзгәреш кертелмәгән булса (монополиягә каршы орган белән килештерү йомгаклары буенча үзгәртелгән нигезләмәләрдән тыш), координацияләү органы өстәмә килешү кергән көннән алып өч эш көне эчендә аны Татарстан Республикасы Премьер-министрына килештерүгә җибәрә.

Координацияләү органы өстәмә килешүне Татарстан Республикасы Премьер-министры белән килештергән көннән алып өч эш көне эчендә аны Татарстан Республикасы Рәисенә кул куюга җибәрә.»;

4.11 пунктта тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен тиешле килешләрдәге «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.13 пунктта татар текстында «турында» сүзеннән соң «Татарстан Республикасы Рәисенә,» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин